ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

9 июнь 2017 ел. № 3530

Башкарма комитетның 2015 елның 24 декабрендәге 7379 нчы карары белән расланган капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе турында нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2015 елның 24 декабрендәге 7379 нчы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 9 декабрендәге 6589 нчы карары редакциясендә) белән расланган капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе турында нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктта:

- «шул исәптән» сүзләреннән соң «чикләүче җайланмалар (капкалар, кечкенә капкалар, шлагбаумнар, шул исәптән автомат һәм декоратив киртәләр (коймалар)» сүзләрен өстәргә;

- «муниципаль норматив хокукый актлар» сүзләрен «гамәлдәге законнар» сүзләре белән алыштырырга;

2) 8 пунктта «хуҗа ачыкланган» сүзләрен «күрсәтмәне алудан баш тарткан» сүзләре белән алыштырырга;

3) 9-10 пунктларны яңа редакциядә бәян итәргә:

«9. Объект хуҗасы ачыкланмаган очракта, район Хакимиятенең вазыйфаи затлары күрсәтмәнең күчермәсен турыдан-туры объектка урнаштыралар һәм бу хакта күрсәтмә бланкында билгеләп куела. Күрсәтмә күчермәсен урнаштыру фото яисә видеога төшереп теркәлә. Шулай ук бу очракта, район Хакимиятенең вазыйфаи затлары, киләчәктә «Интернет»

челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру һәм «Челнинские известия» газетасында бастырып чыгару өчен, өч эш көне эчендә күрсәтмәнең күчермәсен Бүлеккә юллый.

10. Бүлек, әлеге нигезнамәнең 9 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән соң өч эш көне эчендә, аны «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны һәм «Челнинские известия» газетасында бастырып чыгаруны тәэмин итә»;

4) түбәндәге эчтәлектәге 10.1 пункт белән тулыландырырга:

«10.1. Капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектны демонтажлау турындагы күрсәтмә белән объект хуҗасына хәбәр итү датасы булып түбәндәгеләр санала:

1) объект хуҗасын капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектны демонтажлау турындагы күрсәтмә белән таныштыру датасы;

2) капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектны демонтажлау турындагы күрсәтмәне «Челнинские известия» газетасында бастырып чыгару датасы;

3) капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектны демонтажлау турында күрсәтмәне җибәрү турындагы белдерү кәгазе белән заказлы хатны почта бүлекчәсенең кире кайтару датасы (адресатның аны алудан баш тартуы, күрсәтелгән адрес буенча адресатның булмавы, саклану срогы чыгу һәм башкалар)»;

5) 11 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«11. Объектны законсыз урнаштырган объект хуҗасы, күрсәтмә кулга тапшырылган, почта аша алынган, «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырылган, «Челнинские известия» газетасында бастырып чыгарылган вакыттан соң 14 көн срокта, үз көче белән һәм үз хисабына объектны демонтажларга һәм объект законсыз урнаштырылган урынны кире элекке хәленә кайтарырга тиеш.

Объект ирекле рәвештә демонтажланган очракта, район Хакимиятенең вазыйфаи затлары әлеге нигезнамәнең 3 нче кушымтасында каралган форма буенча, законсыз урнаштырылган объектны демонтажлау турындагы күрсәтмәне үтәү хакында акт рәсмиләштерә һәм аны өч эш көне эчендә Бүлеккә җибәрә.»;

6) 3 бүлек исемендәге «объектларны» сүзен төшереп калдырырга;

7) 12 пунктта «бүлек» сүзеннән соң «өч эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

8) 22 пунктта «рәисе» сүзен «әгъзалары» сүзе белән алыштырырга;

9) капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе турында нигезнамәгә 2 нче кушымтада «таләпләрне массакүләм мәгълүмат чараларында бастыру яки Интернет челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру» сүзләрен «күрсәтмәне «Челнинские известия» газетасында

бастыру һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру» сүзләре белән алыштырырга;

8) капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе турында нигезнамәгә 4 нче кушымтаны, кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2017 елның 9 июнендәге
3530 нчы карарына
кушымта

Капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе турында нигезнамәгә 4 нче кушымта

Капиталь төзелеш объекты булмаган
законсыз урнаштырылган объектны демонтажлау турында
АКТ

№ «__» ____ 201_ ел

Демонтажлауны башлау: __ сәг. __ мин.
Демонтажлауны тәмамлау: ____ сәг. __ мин.
____ ________ районының демонтажлау буенча комиссиясе
____________________________________________________________
____________________________________________________________
____________________________________________________________
____________________________________________________________
____________________________________________________________
____________________________________________________________ катнашында
(Ф.И.А.и., вазыйфа)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ____________________________ адресы буенча
(объект урнашкан урынның адресы)
____________________________________________________________
____________________________________________________________
(юридик яки физик затның (ШЭ) мәгълүматлары, адресы)
законсыз урнаштырылган объектың мәҗбүри рәвештә демонтажлауны гамәлгә ашырдылар.

Демонтажлау законсыз урнаштырылган объектны демонтажлау турындагы күрсәтмәне үтәмәү хакында «__» ________ 201__ елның № _____ акты белән расланган «__» ________ 201_ елның № күрсәтмәне үтәмәү нигезендә башкарылды.

Визуаль тикшерү нигезендә, демонтажлауга кадәр объектның тышкы торышы:
____________________________________________________________
____________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Объектны ачу башкарылмады (башкарылды) (кирәклесенең астына сызарга).
Объектны сүтү башкарылмады (башкарылды) (кирәклесенең астына сызарга).
Объектны сүтми торып демонтажлау (сүтү) мөмкинлеге булмау сәбәпләре:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Мәҗбүри рәвештә демонтажланган объект түбәндәге адрес буенча җаваплы саклауга тапшырылды:

______________________________________________________________________.

Оешма вәкиле: ________________________________________________
(Ф.И.А.и., вазыйфасы, имза)

__________ районы Хакимиятенең демонтажлау буенча комиссия әгъзалары:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________
(Ф.И.А.и., вазыйфасы, имза)

Шаһитлар:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________
(Ф.И.А.и., паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны, имза)

Акт белән таныштырылды (таныштырылмады)

______________________________________________________________________
(юридик яки физик затның (ШЭ) мәгълүматлары, имза)

Имза куюдан баш тартты ________________________________________
(__________ районының демонтажлау буенча комиссия рәисенең Ф.И.А.и.)

Кушымта:

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә законсыз урнаштырылган объектны демонтажлаганда табылган мөлкәт һәм башка материаль кыйммәтләрнең исемлеге, ____ биттә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова